| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2014 ел Казан № 10-38/кс

***Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча “Төзекләндерү һәм яшелләндерү” МУП күрсәтә торган хезмәтләргә 2015-2017 елларга тарифлар билгеләү турында***

“Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын көйләү нигезләре турындагы” 30.12.2004 ел № 210-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәяләр барлыкка килү һәм тарифларны, өстәмә түләүләрне һәм соң чик индексларны көйләү тәртибе нигезләре турындагы” 14.07.2008 ел № 520 карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча “Төзекләндерү һәм яшелләндерү” МУП күрсәтә торган хезмәтләргә календарь буенча бүленгән тарифларны шушы карарның 1 кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 гыйнвареннан 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Коммуналь комплекс оешмаларының каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендәге җитештерү программаларының төп күрсәткечләрен 2нче кушымтага ярашлы рәвештә, тарифларның шушы карарның 2нче пунктында күрсәтелгән гамәл дәверенә килештерергә.

4. “Төзекләндерү һәм яшелләндерү” МУП Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.12.2009 № 1140 карары белән расланган мәгълүмәт ачу стандартларына ярашлы рәвештә ирекле алынмалы мәгълүмәтне чираттагы көйләү дәверенә тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңармыйча ачарга тиеш.

5. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча хезмәтләргә шушы карар белән билгеләнгән тарифлар Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының “Коммуналь комплекс оешмалары товарлары һәм хезмәтләренең кулланучылар өчен алынмалы булуын билгеләү өчен кулланылучы критерийлар системасын билгеләү турындагы” 24.02.2014 № 56 боерыгы белән билгеләнгән коммуналь комплекс оешмалары товарлары һәм

хезмәтләренең кулланучылар өчен алынмалы булуы критерийларына туры киләләр.

6. Әлеге карар аны рәсми игълан итү көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
21.11.2014 № 10-38/кс карарына
1к кушымтасы

Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча “Төзекләндерү һәм яшелләндерү” МУП
күрсәтә торган хезмәтләргә 2015-2017 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т. №п | Муниципаль берәмлек, коммуналь комплекс оешмасы атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү хезмәтләренә тарифлар, сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2015-30.06.2015 | 01.07.2015-31.12.2015 | 01.01.2016-30.06.2016 | 01.07.2016-31.12.2016 | 01.01.2017-30.06.2017 | 01.07.2017-31.12.2017 |
| | Мөслим муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | “Төзекләндерү һәм яшелләндерү” МУП | 138,22 | 143,22 | 143,22 | 144,12 | 144,12 | 154,78 |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
21.11.2014 № 10-38/кс карарына
2к кушымтасы

## “Төзекләндерү һәм яшелләндерү” МУП каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендәге җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| Коммунпль комплекс оешмасының атамасы | 2015 ел | | | | | 2016 ел | | | | | 2017 ел | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Коммуналь комплекс оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (НДСтан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасының җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (НДСтан тыш) | Показатели производственной программы организации коммунального комплекса, тыс.куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (НДСтан тыш) |
| | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | |
| | Барлыгы | Халык | Бюджет кулла-нучы-лары | Башка куллану-чылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет куллану-чылары | Башка куллану-чылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет куллану-чылары | Башка куллану-чылар | |
| “Төзекләндерү һәм яшелләрдерү” МУП | 7,2 | 3,3 | 2,2 | 1,7 | 1 013,18 | 7,4 | 3,5 | 2,2 | 1,7 | 1 063,17 | 7,9 | 4,0 | 2,2 | 1,7 | 1 180,63 |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге